

Типичное Тювеево (Тәви авылы татарча) дигән сайтта, якташлары белән горурланып, Ахмәдулла Каюм улы Байкеев турындагы «Темников хәбәрләре» газетасында С.Кудакова мәкаләсен урнаштырганнар. Анда болай диелгән: «Интересная статья о нашем односельчанине». Эчтәлеге тvбәндә.
Тормышында ике ел Афганстан булган Ахмәдулла Каюм улы Байкеевнын турында сойлим.      Кvрсәткән батырлыклары очен ул «Батырлык очен», «Сугышчы-интернационалистка Рәхмәтле Афган халкы исеменнән», II һәм III дәрәҗә «Фидакарь хезмәт очен», III дәрәҗә «Хәрби хезмәттәге казанышлары очен», «Саур революциясенә 10 ел» медальләре, шулай ук СССР Югары Советы Президиумынын Мактау грамотасы белән бvләкләнгән.
Батыр, матур ир-ат Темников районы Айкеево авылында туган, Аксёл-Аксел урта мәктәбен тәмамлаган. Хәзерге вакытта гаиләсе белән Русское Тювеево авылында яши. Гаиләдә алар дvрт бала булып vсәләр: оч абыйсы һәм сенлесе була. Әтисе - Каюм Ибраһим улы, Фин һәм Боек Ватан сугышында катнашкан кешеләрнен берсе.
Ахмәдулла Каюм улы мәктәпне тәмамлаганнан сон, 1962нче елда, Совет Армиясе сафларына алына. Конбатыш Казахстандагы ПВО гаскәрләрендә - Форд Шевченкода хезмәт итә. Станциядән ерак тvгел Юста Бистәсе (Калмыкия) урнашкан була. Биредә, авыл клубында, Ахмәдулла Зифа исемле чибәр кыз белән дә танышырга олгерә. Яшьләрдә хис-тойгылар уяна, сигез айдан алар ойләнешәләр.
Зифа Ибраһим кызы, Элистада педагогика училищесын тәмамлап, жирле мәктәпнен башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшли. Ул ун бала тәрбияләнгән кvп балалы гаиләдә туа. Әнисе Маһирә Әхмәд кызы, «Герой-Ана» медале белән бvләкләнгән, әтисе Ибраһим Давыд улы Умеров, РСФСРнын атказанган укытучысы, Ленин ордены кавалеры. Зифа Ибраһим кызы тумышы белән Әстерхан олкәсеннән, Сиитовка авылыннан. Бvген Сиитовка урта мәктәбе анын әтисе исемен йортә. Ахмәдулла Каюм улы Байкеев vзенен тормыш юлдашын бик ярата һәм анын турында шатланып болай дип йортә: «Хатыным, хужабикәм, ул минем очен ин-иннәрдән дә яхшы!» Ә ул чакта, оч ел хезмәт итеп, ул сверхсрочник буларак артык вакытка хезмәттә кала. Локатор станциясе начальнигы һәм рота старшинасы булып хезмәт итә. Ике елдан сон аны Грозный шәһәренә, прапорщиклар мәктәбенә белем алырга дип жибәрәләр.

Генерал Алексеев житәкчелек иткән зур Ставрополь каналы тозелешендә катнашу анын тормышында яна этап булып тора. Аннан сон - Германия, Магдебург шәһәрендә; анда 5 ел мотоукчылар гаскәрләрендә, дәvләт чиген ябу полкында, аннан сон - Балтыйк буе, Калининград шәһәрендә хезмәт иткән. Биредә армия штабында КП взводы командиры була.
Бу вакытта Афган сугышы бара. Сугыш анын тормышында аерым урын ала. 1943 елда туган Ахмәдулла Каюм улы малай-шалай булып тvгел, ә олы яшьтәге кеше буларак, Афганстанда барган сугышка ике елга эләгә.
Таулар һәм тvбә остендәге кvк, шартлаулар, атучылар... алар хәзер дә анын хәтерендә. Кvргәннәреннән әле дә котылу момкин тvгел. Шул вакыт vлем каядыр янәшәдә йори: кемнедер кичерә, ә кемнедер - юк. Бу Афганстандагы коточкыч, куркыныч, намуссыз сугыш кvп кенә кешеләрнен язмышларын юкка чыгарды.
Кабул, Кандагар, Шиндант, Герад автобазаларында ягулык vткәргечен саклау. Алар алдында куелган бурыч - истребительләрне һәм вертолетларны ягулык белән тәэмин итv. Душманнар еш кына стратегик яктан моһим объектны шартлаткан һәм аларны тозәтергә дип совет солдатлары бронетранспортерларда ашыгыч формада барганнар. Ә душманнар сугышчыларнын ягулык vткәргечендәге тишекне тозәтергә килvләрен котеп кенә тора булганнар. Һәм бу мизгелдә аларны гранатометтан һәм башка ату коралыннан атып торалар. Ахмәдулла Каюм улы шундый «ит тарткычта» булган кешеләрнен берсе. Бронетранспортер ватыклары аягын яралый; шул ук вакытта шофер, казак милләтле Юсуповнын кулын озә. Мондый имгәнvләр сирәк булмый торган булган шул вакытта. «Рейдларга йордек, - дип искә ала Ахмәдулла Каюмович, - адым саен фажига котеп торды, сагалады, чонки тауларда бандит формированиеләре кvп иде». Ә оендә гаиләсе - хатыны һәм ике баласы котеп торды. Кызы Галия, 10 сыйныфта укый торган иде, ә улы Таһир, армиядә хезмәт итте. Бу елларда Ахмәдулла белән Зифа хат язышуны бик актив алып бардылар. Һәр хатта да бер-берсен чын кvнелдән яратулары турында яздылар. Аерылышуны бик авыр кичерделәр алар. Зифа Ибраһим кызы әле дә бу хатларны кадерләп саклый.
Ахмәдулла Байкеев Афганстанда булганда, әтисе Каюм вафат була. Улын жирләvгә жибәрәләр. Мәскәvдә аны хатыны һәм балалары каршы ала. Ә жирләнгәннән сон, тагын бер кат аерылышу, янә Афган!
Мордовияга, Темников районындагы ту-ган  урыннарына, 2001 елда гына хезмәт итеп кайткан язма героебыз. Һәр ел Совет гаскәрләрен  Афганстаннан  чыгару коннәрен кvнелендә зур горурлык хисе белән каршылый, чонки гаиләгә әйләнеп кайткан, исән калган язмышка рәхмәтле. Ахмәдулла Каюм улы Байкеевнын мактауга лаеклы хезмәтен Ватаныбызнын билгеләп vтvе белән якташлары да горурлана. Ә Ахмәдулла Каюм улы Байкеевка бигрәк «Батырлык очен» медале кадерле, һәм бу анлашыла да: Боек Ватан сугышы ел-ларында нәкъ менә шушы медаль фрон-товикларнын яраткан бvләкләре булды.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**